

**/Безнең бәйрәмнәр/**

## Өлкәннәрне хөрмәт итик!

Октябрь аенда ике зур бәйрәм бар – Өлкәннәр көне һәм Укытучылар көне. Менә шуны истә тотып, мәктәбебезгә ветеран укытучыларны һәм лаеклы ялда булган мәктәп хезмәткәрләрен очрашуга чакырдык. Очрашу һәрвакыт җылы истәлекләргә бай була. Бу юлы да өлкәннәребез яшь чакларын, эшнең төрлесен эшләгәннәрен искә алдылар. Үз чорларының кызыгы да, авырлыгы да бергә барганлыгын бүгенге хезмәткәрләргә тыңлавы кызык булды.Бакчага йөрүче нәниләр һәм укучылар кунакларга концерт номерлары күрсәтте. Кунакларыбызны да буш утыртмады, гармунга матур җырлар суздылар, төрле кызыклы хәлләрне сөйләделәр.Очрашу матур һәм күңелле узды.

*Кәүсәр Насыйрова, VIII сыйныф укучысы*

## Уңыш бәйрәмендә – КВН



Көзге уңыш бәйрәме – уку елының иң күңелле вакытларының берсе. Зал бәйрәмчә бизәлгән, сәхнәдә алтын яфраклар, мул уңыш күргәзмәсе. Бәйрәмгә килүчеләрнең күңеле күтәренке.

Мәдәният йортында 25нче октябрь көнне, V-IX сыйныф укучыларының "Уңыш бәйрәме" булып узды. Чара КВН формасында үтте. "Яшьлек" һәм "Ялкын" командалары узара көч сынашты, ә V һәм VI сыйныфлар ярышлар арасында үзләренең матур чыгышларын күрсәттеләр. Командалар жюри әгъзаларын һәм тамашачыларны үзләренең осталыклары белән шаккатырырга әзер иде. Бәйге программасына елдагыча таныштыру, көлкеле скетч һәм пантомимо, нәфис сүз, бию кебек төрләр кертелгән иде. Ярышучылар үзләренең осталыкларын төрлечә күрсәттеләр.

Командаларны җитәкләгән Гафиятуллина Фәнүзә апа белән Сафиуллина Алсу апа, Закирова Гөлшат апалар безнең уңышлы чыгышыбыз өчен бик тырыштылар. Команда белән эшләүнең уңай ягы күп булганга, бу бәйрәм һәрберебезгә ошый. Чөнки бер эшне бернichә иптәшең белән башкарып чыгу өчен барлык мөмкинлекләрдән файдаланырга тырышасың, эзләнәсең. Кемнеңдер шул вакытта оештыру сәләте ачыла. Кайберләребезнең сәхнәдә чыгышы башлана. Тапкырлыкка, зирәклеккә, җитезлеккә өйрәтүе белән файдалы ул КВН. Кул астында булган чималлар эшкә җигелә. Тиз арада җиңел ысул уйлап, уеңны чынга ашырасың. Иң беренче, исем, девиз, җыр уйлап табудан башлыйсың инде. Аңа ияреп башка биремнәрне дә үтибез. Аларны үтәр өчен никадәр театр, скетч карап тәҗрибә туплыйбыз. Бию төрләрен өйрәнәбез.

Командаларның ярыш нәтиҗәләрен караганда, без ныклы команда идек. Ләкин ярыш – ярыш инде ул. Шулай итеп, "Яшьлек" командасы 87 балл белән беренчелеккә чыкты, ә "Ялкын" командасы 86 балл белән җиңелде.

*Ләйсән Закирова, VIII сыйныф укучысы*

**/Укучылар иҗаты/**



## Көз-муллык вакыты

Көз – елның бер могҗизасы. Җәйнең эссе тынлыгыннан соң, табигать әкренләп яңа төсләргә күмелә. Алтынсу сары, кызыл, көрән төсләр агачларны бизәгәндә, урманнар сихри бер дөньяга әверелә.

Көз – уңыш вакыты, муллык һәм байлык бәйрәме. Кырларда комбайннар көн-төн эшли, алтын башакларны җыеп ала. Басулар икмәк исе белән тула, ә хуҗаларның йөзләрендә шатлык балкый. Бакчаларда алмалар, грушалар өлгерә. Барлык бакча муллыгы кояшта җемелдәп тора. Көз – табигатьнең рәхмәте, җирнең кеше хезмәтен бүләкләү чоры.

Көз көннәре салкынча, ләкин кояш әле һаман да җылыта. Агачлардан яфраклар коела, җиргә алтын келәм җәя. Балалар яфраклардан төрле уенчыклар ясый, ә олылар табигатьнең соңгы матурлыгыннан ләззәт ала. Көз – уйлану, хыяллану вакыты. Чөнки инде уңыш җыелып урнаштырылган. Ашыкмый гына, уйландыра торган озын кичләр вакыты.

Көз – кошларның җылы якка китү чоры да. Күктә кыр казларының авазы ишетелә, алар саубуллашып, ерак юлга чыга. Көз – табигатьнең йокыга әзерләнүе, яңа көч җыю вакыты.

Көз – елның иң матур фасылларының берсе. Ул безгә муллык, байлык, шатлык һәм тынычлык бүләк итә. Безгә шушы иркенлекне файдаланып, тырышып укырга гына инде.

*Настя Сафеева, VIII сыйныф укучысы*

**Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе**
**Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина**
**Редколлегия әгъзалары – Асия Нурматова, Кәүсәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Настя Сафеева, ???**

# Мәктәп хәбәрчесе

**№8 (№69) октябрь 2025 ел**


**Түбән Майна урта мәктәбе газите**

**Тел. 8 (84344) 4-38-46** **sch1644maina@mail.ru**

**/Мөгаллим киңәше/**

## «Киләчәккә билет" – тәрбия эшенең яңа юнәлеше

2022нче елның сентябреннән мәктәпләргә президент В.В.Путин фәрманы белән Россиянең 45 регионында тәрбия эшләре буенча директор киңәшчесе вазифасы кертелде. Бу вазифаның төп бурычы булып укытучы, укучы, эти-әниләрне уртак проектлар ярдәмендә берләштерү, мәктәп эшчәнлегендә һәм мәктәптән тыш тормышка яңача караш тудыру,тәрбия эшен максатлы һәм заманча алып баруны булдыру.




Тәрбия эшләре буенча директор киңәшчесенең эшчәнлеге нидән гыйбарәт соң?

- Мәктәпнең тәрбия эше программасы, укытучыларның эш программалары төзүдә катнашу;
- Укучыларның "Беренчеләр хәрәкәтен" җитәкләү;
- Укучыларны тәрбия эшләре аша иҗади эшчәнлеккә юнәлтү;
- Укучыларның дәрестән тыш һәм каникул вакытларын оештыруда катнашу.

Киңәшчеләрнең эшчәнлеге Россия координаторлары тарафыннан җибәрелгән концепциягә нигезләнеп башкарыла. Укучылар белән сыйныф сәгатьләре, диспут, викторина, төрле ярышлар, иҗади эшләр һ.б.чаралар үткәрелә. Нәтиҗәләре сайтларда яктыртылып килә. Шулай бергәләшеп эшләгәндә генә тәрбия эше уңышлы нәтиҗәсен бирер дип уйлыйм. Юкка гына күренекле галим-мәгърифәтче, тарихчы һәм педагог Ризаэтдин Фәхретдин "Бала чакта алынган тәрбияне соңыннан дөнья халкы үзгәртә алмас" димәгән.

Быелгы уку елыннан башлап укучылар цифрлаштырылган платформа –**"Киләчәккә билет"** проектына кертелде. Бу проектка 6-11 сыйныф укучылары теркәлеп, шәхси кабинетларын булдырдылар. Проектның эшчәнлеге этаплап башкарыла. Беренче этапта укучылар "Россия– минем горизонтым" дип исемләнгән курс аша дөньядагы төрле һөнәрләр белән танышып мәгълүмат туплый. Икенче этапта онлайн-диагностика үтелә. Өченче этап – профессиональпроба. Бу этапта укучылар төрле практик мәсьәләләр чишә.Практик дәресләр укучыларга белемнәрен кулланыргаярдәм итә. Дәресләрдән соңукучылар каршы анкета ярдәмендә үзфикерләрен җиткерә ала.

Укытучы өчен дәрес материалы да шушы платформада урнаштырылган.Мин педагог-навигатор буларак, бу курсның хәзерге заман укучысы өчен бик мөһим булуын әйтә алам. Әлеге проект укучыларга тегe яки бу һөнәр иясе булу өчен нинди күнекмәләр, сыйфатлар кирәклеген ачыкларга, үзләренең талантларын ачарга ярдәм итә.

"Киләчәккә билет" проекты хәзерге яшь буынның тормышын бары тик яхшы якка үзгәртер һәм тормышта үз юлын табарга өйрәтердипышаныпкаласыкилә.

*Гөлфия Әхмәтҗанова, тәрбия буенча директор киңәшчесе*




## Һөнәри бәйрәмнәрегез белән! **/Котлыйбыз!/**

Хөрмәтле мөгаллимнәр! Сезне чын күңелдән 5 нче октябрь – **укытучылар көне** белән котлыйбыз! Үзегезнең тирән белем һәм сабырлык белән биргән дәресләрегез юлыбызга җилкән булыр. Хыялларны чын итәрлек тырышлыкка өндәгәнегез өчен рәхмәт. Безнең балачакның һәр шуклыгына түзеп, кирелеген сүтеп, уңай якка юлыбызны үрәсез. Сабырлык белән белемне тигез өләшәсез. Сезгә эшегездә иҗадилык, гаиләгезгә иминлек, сәламәтлек телибез!




20 нче октябрь ил күләмендә пешекчеләр көне буларак билгеләп үтелә. Ризык әзерләү бик җиңел эш түгел, һәр ризыкка күңел җылыңны салып эшләсәң генә, ул тәмле була.

Хөрмәтле пешекчеләребез! Сезне һөнәри бәйрәмегез белән тәбрик итәбез! Күңел җылыгыз һәрчак мул булсын, табаларыгыз чыжлап торсын, ризыкларыгыз мактаулы булсын! Укучыларның тамагы тук булганда гына белем биреп була! Үзегезгә сәламәтлек, хәерле матур гомер, гаилә бәхете телибез.

*"Мәктәп хәбәрчесе" редколлегиясе*

## Беренче чирек нәтиҗәләре *‍/Рәсми хәбәрләр/*

Октябрьнең 26 сында уку елының I чиреге дә тәмамланды. Бу чиректә 39 укучының 38 сенә билгеләр чыгарылды. Белем сыйфаты 47,37% кына тәшкил итте. Моңа берәр "өчле" белән төшеп калган укучыларыбызның тырышлыгы җитеп бетмәү сәбәп булды. Уку отличниклары – IV сыйныфтан**Гафиятуллина Руфина** һәмV сыйныф укучылары **Закиров Инсаф** белән **Камалов Илнур**;VI сыйныфтан **Нурматова Асия**, VIII сыйныфтан **Закирова Ләйсән**. Көзге каникуллар 27нче октябрьдән 6нчы ноябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

***Илдар Сафиуллин, уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары***

## Октябрь ае вакыйгалары */Мәктәп тормышы/*



Халыкара музыка көне дөньякүләм дәрәҗәдә 1 октябрьдә билгеләп үтелә. Музыка ничек барлыкка килгән? Бу сорауга җавап бирү шактый кыен. Әмма музыканы күп кешеләр ярата. Менә безнең егетләр дә искәрмә түгел. Халыкара музыка көнендә безнең мәктәптә тәнәфесләрдә, музыка дәресләрендә бөек композиторларның музыкаль композицияләрен тыңладылар. Алтынчы сыйныф укучылары өчен "Музыка минем өчен нәрсә аңлата?" дигән викторина да оештырдылар.

Халыкара хайваннарны яклау көне 4нче октябрьдә билгеләп үтелә. Бу датаны бәйрәм итү уңаеннан башлангыч сыйныфлар сыйныф җитәкчеләре һәм тәрбия буенча киңәшче белән берлектә "Минем кадерле дустым"темасына акция үткәрделәр. V сыйныф укучылары "хайваннар дөньясы: серләр һәм табышмаклар"викторинасында катнаштылар. Ә VI-IX сыйныфлар өчен сыйныф сәгатьләре үтте. Укучылар барысы да бик тырыштылар. Алар хайванның безнең кече туганнарыбыз булуын һәм аларның яклауга мохтаҗ булуын искә төшерделәр.



Ел саен 5нче октябрьдә илебездә матур бәйрәм - Укытучылары көне билгеләп үтелә. Нәкъ шул көнне безнең кадерле мөгаллимәләребезгә рәхмәт сүзләре әйтелә. Безнең мәктәптә бәйрәм көне традицион үзидарә көне белән башланды. Өлкән сыйныф укучылары үз вазифаларына намус белән карадылар. Алдан дәресләр расписаниесе төзелеп, укытучы-дублерлар дәресләрне бүлештеләр, сыйфатлы дәресләр күрсәттеләр.



Эш беткәч уйнарга ярый дигәндәй, 17нче октябрь көнне мәктәбебездә, башлангыч сыйныф укучылары арасында гөрләтеп уңыш бәйрәме узды. Бәйрәм өч өлештән торды. Беренче өлеш – көзгә багышланган иҗади кул эшләнмәләре ясаудан гыйбарәт булды. КВН формасында үткән икенче өлештә укучылар тапкырлыкта,зирәклектә көч сынаштылар. Өченче өлеш, бәйрәм табыны артында, чәй эчү белән дәвам итте. Балалар бәйрәмнән бик канәгать калдылар, үзләренә кирәкле бик күп мәгълүматлар алдылар.




19нчы октябрь – Әтиләр көне. Мәктәптә әтиләргә багышлап сыйныф сәгатьләре, уен-дәресләр үткәрелде. Яклаучыларыбыз һәм саклаучыларыбызны бәйрәмнәре белән котладык. Әти – тормышта һәрчак төгәллеге белән, аз сүзле, ләкин төпле акылы белән юл күрсәтүче. Хөрмәтле әтиләр! Улыгыз, кызыгызның игелеген күреп, тигез тормышта яшәгез. Балаларыгыз – сезнең белән, сез балаларыгыз белән горурланып яшәрлек булсын. Бәхетле булыгыз!

Безнең мәктәп 27нче октябрьдә билгеләп үтелә торган халыкара мәктәп китапханәләре көнен бәйрәм итүдә катнашты. Интернет булуга, һәр илдә, дистәләгән, миллион электрон китапка карамастан, яңадан-яңа китапханә биналары төзелә, аларның кайберләре чын архитектура шедеврларына әверелә. Шушы датада V-VII сыйныф укучылары дөнья китапханәләре буйлап виртуаль сәяхәт иттеләр. Ә башлангыч сыйныф укучылары китапларның әкият битенә сәяхәт оештырдылар. Алар алып баручылар ролена кerделәр, әкиятләрнең эчтәлеге турында фикер алыштылар һәм әкиятләрнең гыйбрәтле мәгънәсе турында сөйләделәр

***Хәбәрләрне "Мәктәп хәбәрчесе"редколлегия әгъзалары әзерләде***

## */Котлыйбыз!/*



Октябрь аенда дөньяга килгән дусларыбыз – IV сыйныфтан **Хафизов Илфатны**, V сыйныфтан **Закиров Инсафны**, IX сыйныфтан **Хәбибрахманова Хәнифәне** туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында уңышлар теләп калабыз!

Башлангыч сыйныф укытучысы **Камалова Сирин апаны** гомер бәйрәме белән котлап, саулык-сәламәтлек, эшендә уңышлар, гаилә иминлеге телибез!

## Алабуга укытучыларны кабул итте */Безнең сәяхәтләр/*



Укытучылар көне уңаеннан, көзнең бер матур көнендә без мәктәп коллективы һәм лаеклы ялдагы хезмәттәшләребез белән Кама ярларында урнашкан борынгы Алабуга шәһәренә мавыктыргыч сәяхәт кылдык. Әлеге сәфәр күңелле ял гына түгел, ә туган ягыбыз тарихына, мәдәниятенә яңача карарга мөмкинлек биргән кыйммәтле тәҗрибә дә булды.

Шәһәргә барып җиткәч, беренче тукталыш Алабуга дәүләт музей-тыюлыгы иде. Әлеге экскурсия ярдәмендә без тулысы белән элеккеге сәүдәгәр Алабугасы атмосферасына чумдык. Шәһәрнең тарихы, күренекле кешеләре һәм тарихи вакыйгалары турында күп мәгълүмат тупладык. Җирле халыкның гореф-гадәтләре һәм көнкүреше турында өйрәндек.

Шуннан соң без риваятьләр белән уратылган борынгы җирлек – Шайтан шәһәрчегенә бардык. Калкулыкка менеп бормаланып аккан Чулман елгасы һәм шәһәр тирәсендәге гаҗәеп матур табигать күренешләренә сокландык. Экскурсовод безне бу урынның тарихы белән таныштырды, аның археологик әһәмияте һәм аның атамасының килеп чыгышы турындагы версияләрне сөйләде.

Экскурсиябезнең йомгаклау өлешендә юлыбыз А.А. Шишкинның мемориаль комплексына юнәлде. Без бөек рус рәссамының чын картиналарына гына сокланып калмадык, ә аның тормышы, иҗат юлы, туган ягына булган мәхәббәте турында да мәгълүмат белдек. Шишкинның иҗаты аша без тагын бер кат туган ягыбызның матур һәм бай табигатьле икәненә инандык. Минем уйлавымча, музейдагы атмосфера һәр кешенең йөрәгендә онытылмас эз калдыргандыр.

Экскурсия укытучыларга яңа белемнәр генә түгел, ә күңелле ял да бүләк итте. Алар көндәлек эшчәнлектән арынып, мәдәни мирасыбыз белән таныштылар һәм хезмәттәшләре белән аралашу мөмкинлегенә ия булдылар. Бу сәяхәт укытучыларның рухын күтәрергә һәм яңа уңышларга илһамландырырга ярдәм итте.

***Гөлшат Закирова, рус теле һәм әдәбияты укытучысы***

## Көзге каникул сәфәре



31нче октябрь көнне VII - IX сыйныф укучылары Казанга экскурсиягә барып кайттык. Без мәктәп автобусында иртәнге җиденче яртыларда юлга чыктык. Җитәкчеләребез буларак, укытучылардан Фәнүзә һәм Алсу апалар барды.

Казанга барып җитүгә иң баштан "Фән һәм техника" музеена кердек. Бу музейда физика, химия, биология һәм башка фәнни өлкәләр белән бәйле экспонатларны күрдек. Шулай ук, роботлар, компьютерлар һәм башка заманча техника үрнәкләре белән таныштык Укучылар экспонатлар белән интерактив режимда эшләделәр, төрле тәҗрибәләр үткәрделәр һәм фәннең кызыклы дөньясына чумдылар. Экскурсия балаларга фән һәм техника турында яңа белемнәр генә бирмәде, ә аларның иҗади һәм логик фикерләү сәләтләрен үстерергә ярдәм итте. Мин үзем дә җитәкче янына чыгып эксперимент күрсәттем. Шундый тәҗрибәле өлешләре бигрәк тә ошады. Икенче катта безгә безгә 3D принтер турында сөйләделәр, анарда бик күп матур, кызык әйберләр ясап булганын аңлаттылар. Ул прибор безнең мәктәптә дә булгач, үземне кыюрак та тоттым. Бу музейдагы экскурсия балаларга фән дөньясына керергә, заманча технологияләр белән танышырга һәм яңа ачышлар ясарга мөмкинлек бирде.

Төшке аш ашаганнан соң татар халкының бөек шагыйре Габдулла Тукай музеенда булдык. Бу сәяхәт Тукайның тормышы һәм иҗаты белән якыннан танышырга, аның шигырьләренең рухи дөньясына керергә мөмкинлек бирде. Музейда без шагыйрьнең балачагы, яшьлек еллары, иҗат юлы турында мәгълүмат алдык. Тукайның шәхси әйберләрен, китапларын, кулъязмаларын күрдек. Шулай ук, шагыйрьнең дуслары һәм замандашлары турында кызыклы мәгълүмат алдык. Экскурсия безгә Тукайның иҗаты турында яңа белемнәр генә бирмәде, ә аларның татар әдәбиятына һәм мәдәниятенә мәхәббәтен арттырды.



Өченче тукталышыбыз "Милли музей"да булды. Монда татар халкының тарихы, мәдәнияте һәм гореф-гадәтләре белән якыннан таныштык. Халкыбызның борынгы заманнардан бүгенге көнгә кадәрге тарихы турында мәгълүмат алдык. Без археологик табылдыкларны, көнкүреш әйберләрен, милли киемнәрне, сәнгать әсәрләрен күрдек. Татар халкының тарихындагы күренекле шәхесләр турында белдек, аларның тормышы һәм эшчәнлеге белән таныштык. Шулай ук, музейда татар халкының гореф-гадәтләре һәм йолалары турында кызыклы мәгълүмат алдык.

Йомгаклап әйткәндә, сәфәребез киң колачлы булды. Татар халкының тарихы, Габдулла Тукай турында яңа белемнәр, техника турында да кызыклы мәгълүматлар тупладык. Сәяхәттән бай тарихлы туган ягыбызны һәм башкалабыз Казан каласын тагын да яратып кайттык. Шәхсән үземдә бу сәяхәт фәннәр белән кызыксынуымны күпкә арттырды.

***Настя Сафеева, VIII сыйныф укучысы***